**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.03.2017 № 163

г.Казань

**2017 елда үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына айлык тикшерү үткәрү тәртибен раслау турында**

“Өлкән яшьтәге кеше өчен үзенә сыендырган гаилә” пилот проектын тормышка ашыру турында” 31.08.2016 ел, № 604 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ буларак танылган үз акылындагы өлкән яшьтәге гражданнар өчен үзенә сыендырган гаиләләр булдыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 3.10 пунктындагы 1 пунктчасын тормышка ашыру максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. 2017 елда үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына айлык тикшерү үткәрү тәртибен (алга таба - Тәртип) (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре директорларына үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына айлык тикшерү үткәргәндә бу боерык белән расланган Тәртипкә таянырга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының методология бүлегенә бу боерык белән расланган Тәртипне тормышка ашыруда Татарстан Республикасы халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре белгечләренә методик ярдәм күрсәтергә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Ю.И.Абдреевага йөкләргә.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау
министрлыгының
«21» март, 2017 ел, № 163
боерыгы белән расланды

**2017 елда үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына айлык тикшерү үткәрү тәртибе**

1. 2017 елда үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына айлык тикшерү үткәрүнең бу тәртибе (алга таба – Тәртип) "Өлкән яшьтәге кеше өчен үзенә сыендырган гаилә" пилот проектын тормышка ашыру турында" 31.08.2016 ел, № 604 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ буларак танылган үз акылындагы өлкән яшьтәге гражданнар өчен үзенә сыендырган гаиләләр булдыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә туры китереп булдырылган үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына айлык тикшерүне Татарстан Республикасы халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре тарафыннан үткәрү кагыйдәләрен билгели.

2. Бу Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр "Өлкән яшьтәге кеше өчен үзенә сыендырган гаилә" пилот проектын тормышка ашыру турында" 31.08.2016 ел, № 604 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында (алга таба – Карар) билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

3. Үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына айлык тикшерү (алга таба – яшәү шартларын тикшерү) үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына тикшерү үткәрүгә Татарстан Республикасы халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге (алга таба – Комплекслы үзәк) директоры боерыгы (алга таба – Комплекслы үзәк боерыгы) белән вәкаләт бирелгән Комплекслы үзәк белгечләре тарафыннан хәл ителә.

4. Яшәү шартларына тикшерү үткәрү Комплекслы үзәкнең ике белгече тарафыннан, өлкән яшьтәге гражданин өчен үзенә сыендырган гаилә булдыру турында килешүдә күрсәтелгән үзенә сыендырган гаиләнең яшәү урынында (алга таба – үзенә сыендырган гаиләнең яшәү урыны) булып кайту рәвешендә, хәл ителә. Яшәү шартларына тикшерү үткәрүгә нигез булып Комплекслы үзәк боерыгы тора.

Комплекслы үзәк белгечләре яшәү шартларына тикшерү үткәргәндә өлкән яшьтәге гражданинга һәм ярдәмчесенә хезмәт таныклыкларын һәм комплекслы үзәк директоры раслаган Комплекслы үзәк боерыгы күчермәсен күрсәтергә тиеш.

5. Яшәү шартларына тикшерү үткәрү барышында:

а) үзенә сыендырган гаилә булдыру турында килешүдә билгеләнгән өлкән яшьтәге гражданинны карау тәртибе һәм шартларыннан чыгып, үзенә

сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартлары өйрәнелә, шул исәптән:

торакта өлкән яшьтәге гражданинның шәхси почмагының торышы;

өлкән яшьтәге гражданинның үзенә сыендырган гаилә әгъзаларының гомуми файдалануындагы бүлмәләрдән һәм әйберләрдән файдалану мөмкинлеге;

өлкән яшьтәге гражданинның файдалануындагы торакның һәм әйберләрнең торышы, шул исәптән аларның санитария-гигиена таләпләренә һәм кагыйдәләренә туры килүе;

б) өлкән яшьтәге гражданинның ярдәмчесенең яшәү урынында булмау факты билгеләнә.

6. Яшәү шартларына тикшерү үткәрү аена бер тапкыр хәл ителә.

Агымдагы айда яшәү шартларына тикшерү үткәрү датасы, ярдәмче белән килештереп, Комплекслы үзәк белгече тарафыннан билгеләнә. Комплекслы үзәк белгече яшәү шартларына тикшерү үткәрүнең күздә тотылган датасына кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча, үзенә сыендырган гаиләнең яшәү урыны буенча Комплекслы үзәкнең эш вакытында һәм эш көннәрендә яшәү шартларына тикшерү үткәрү датасын һәм вакытын ярдәмче белән килештерә.

7. Яшәү шартларын тикшерү вакытында өлкән яшьтәге гражданин, туганнарына, медицина яки санаторий-курорт оешмаларына китүе сәбәпле, үзенә сыендырган гаиләнең яшәү урынында булмаган очракта, булмавының сәбәбе турында ярдәмчесе Комплекслы үзәк белгечләренә хәбәр итә.

Комплекслы үзәк белгечләре яшәү шартларына тикшерү үткәргәннән соң өлкән яшьтәге гражданинның кайда икәнлеген билгеләү максатыннан чыгып чаралар үткәрә.

8. Яшәү шартларына тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча, бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендәге формага туры китереп, үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына тикшерү үткәрү турында акт (алга таба – акт) төзелә.

Акт турыдан-туры яшәү шартларына тикшерү үткәргәндә, бер үк төрле юридик көчкә ия булган өч нөсхәдә, төзелә.

Актның барлык нөсхәләренә Комплекслы үзәк белгечләре, өлкән яшьтәге гражданин һәм ярдәмчесе имза сала. Өлкән яшьтәге гражданин һәм (яки) ярдәмчесе мондый актка имза салудан баш тарткан очракта, актта тиешенчә язып куела.

Актның бер нөсхәсе үзенә сыендырган гаиләнең Комплекслы үзәктә саклanылучы шәхси делосына теркәп куела, икенче һәм өченче нөсхәләре, яшәү шартларына тикшерү үткәргәннән соң, өлкән яшьтәге гражданинга һәм ярдәмчесенә тапшырыла.

Яшәү шартларын тикшерү вакытында өлкән яшьтәге гражданин, туганнарына, медицина яки санаторий-курорт оешмаларына китүе сәбәпле, үзенә сыендырган гаиләнең яшәү урынында булмаган очракта, актка тиешенчә язып куела. Актның өченче нөсхәсе, үзенә сыендырган гаиләгә әйләнеп кайтканнан соң, үзенә сыендырган гаиләдә яшәү шартларына чираттагы тикшерү үткәргәндә, өлкән яшьтәге гражданинга тапшырыла.

Үзенә сыендырган гаиләдә яшәү шартларына тикшерү үткәргәндә булмаган өлкән яшьтәге гражданинның язмача гаризасы буенча, ярдәмчесенең ризалыгы

белән, шушы айда өлкән яшьтәге гражданинның үзе югында яшәү шартларына кабат тикшерү үткәрелергә мөмкин.

9. Комплекслы үзәк белгечләренең яшәү шартларына тикшерү үткәрү өчен үзенә сыендырган гаиләгә барып килүен теркәү, бу Тәртипкә №2 кушымта нигезендәге форма буенча расланган, Үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына тикшерү үткәрү өчен Комплекслы үзәк белгечләренең барып килүләрен теркәү журналында хәл ителә.

Үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына тикшерү үткәрү өчен Комплекслы үзәк белгечләренең барып килүләрен теркәү журналының битләре тегелгән, номер сугылган һәм Комплекслы үзәк мөхере белән расланган булырга тиеш.

2017 елда үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына айлык тикшерү үткәрү тәртибенә №1 кушымта

форма

**Үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына тикшерү үткәрү тәртибе турында акт № ________**

______________________ «__» __________ 20__ ел

*(актны төзү урыны)*

Түбәндәге составта комиссия:

1. _________________________________________________________________,
*(Комплексլы үзәк белгеченең Ф.И.О. һәм вазыйфасы)*
2. _________________________________________________________________,
*(Комплекслы үзәк белгеченең Ф.И.О. һәм вазыйфасы)*

үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына тикшерү үткәрүгә Комплекслы үзәкнең «__» __________ № _____ боерыгы белән вәкаләт бирелгән,

катнашында__________________________________________________________,
*(ярдәмченең Ф.И.О. )*
катнашында (югында) ____________________________________________,
*( өлкән яшьтәге гражданинның Ф.И.О. )*

"Өлкән яшьтәге кеше өчен үзенә сыендырган гаилә" пилот проектын тормышка ашыру турында" 31.08.2016 ел, № 604 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ буларак танылган үз акылындагы өлкән яшьтәге гражданнар өчен үзенә сыендырган гаиләләр булдыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 3.10 пунктындагы 1 пунктчасы нигезендә, түбәндәге адрес буенча үзенә сыендырган гаиләдә ____________________________________________ яшәү шартларына тикшерү
*( өлкән яшьтәге гражданинның Ф.И.О. )*
үткәрде
_________________________________________________________________.
*(үзенә сыендырган гаиләнең яшәү адресы)*

Үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына тикшерү үткәрү йомгаклары буенча билгеләнде (ачыкланды):

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Комиссия әгъзалары имзалары:

__________________ ____________________________

*(имза)* *(Ф.И.О.)*

__________________ ____________________________

*(имза)* *(Ф.И.О.)*

Үзенә сыендырган гаилә әгъзалары имзалары:

өлкән яшьтәге гражданин:___________________________________________

________________________________________________________________________*

__________________ __________________

*(имза)* *(Ф.И.О.)*

ярдәмчесе :_____________________________________________________________

________________________________________________________________________*

__________________ __________________

*(имза)* *(Ф.И.О.)*

________________________________________

* - теләге булганда, өлкән яшьтәге гражданин һәм аның ярдәмчесе өлкән яшьтәге гражданин өчен үзенә сыендырган гаилә булдыру турында килешү буенча бурычларның икенче як тарафыннан үтәлмәве яки тиешенчә үтәлмәве турында фикерен чагылдыруга хокуклы

2017 елда үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына айлык тикшерү үткәрү тәртибенә №2 кушымта

форма

**Үзенә сыендырган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына тикшерү үткәрү өчен**

___

*(Комплекслы үзәк атамасы)*

**белгечләренең барып килүләрен теркәүгә алу журналы**

| № п/п | Тикшерү үткәрү датасы һәм вакыты | Белгечнең Ф.И.О. һәм вазыйфасы | Үзенә сыендырган гаиләнең яшәү урыны адресы | Өлкән яшьтәге гражданинның Ф.И.О. | Ярдәмче сенең Ф.И.О. | Өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына тикшерү үткәрү акты № | Искәрмә (кирәк булганда) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *1* | *2* | *3* | *4* | *5* | *6* | *7* | *8* |
| | | | | | | | |